| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Менделеевский муниципальный район<br>Глава Брюшлинского сельского поселения | Татарстан Республикасы<br>Менделевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге башлыгы |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21 октябрь 2024 ел №2

Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле
торак пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 ноябре 17.00 сәг. Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Бөрешле авылы, Елга аръягы урамы 14 й. адресы буенча урнашкан Бөрешле авыл мәдәният йортында Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. «2025 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан, 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Бөрешле авылында вак таш түшәлгән юлларда чокырларны ремонтлау; Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту);

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Бөрешле авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Бөрешле авылы территориясен чабу)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Бөрешле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А.Смирнова